



"Көмеш кыңгырау" китапханәсе



Бүген укучыларыбызга кайбер кызыклы тәҗрибәләр, фокуслар ясарга өйрәтәбез. Ни өченме? Дусларыгыз, классташларыгызны шаккатырырсыз, көчегезне, осталыгыгызны, белемегезне күрсәтерсез. Уңышлар сезгә!




Читлектәге кош





Тыгыз катыргы, циркуль, карандашлар йә фломастерлар, кайчы, энә-җеп һәм линейка кирәк.

Эш тәртибе:

1. Теләсә нинди диаметрлы әйләнә яса һәм кисеп ал.
2. Әйләнәнең ике ягына энә белән икешәр тишек тиш.
3. Тишекләр аша ике яктан да ярты метр озынлыгындагы җеп үткәр.
4. Әйләнәнең бер ягына буш читлек, икенче ягына кечкенә кошчык яса.
5. Җепнең башыннан тотып әйләнәне бөтерә башла, якынча утызга чаклы санагач, җеп нык кына бөтерелер. Ике ягын да тигез тотып, әйләнәнең кире бөтерелгәнен кара: кош читлектә утырганга охшаган, әйеме?







Әйләнә каян килеп чыкты?

Турыпочмаклы катыргы, карандаш, фломастер һәм линейка кирәк.

Эш тәртибе:

1. Линейканы катыргыга А рәсемендә күрсәтелгәнчә итеп куй.
2. Линейка кырыннан фломастер белән катыргыга 25-30 нокта яса. Ноктаразрның арасы тигез, якынча 0,5 мм булсын.
3. Очлы карандаш белән катыргының уртасын тиш.
4. Карандашны өстәлгә бастырып куй да, катыргыны әйләндерерлек ит.
5. Буш кулың белән катыргыны әйләндер. (Б рәсеме)

Әйләнгән катыргыда түгәрәк барлыкка килер, ә туктагач - бетәр.



Тылсымлы шешә

Лимонадтан бушаган шешә һәм һава шары ал.

Эш тәртибе:

1. Шарны шешә эченә керт, шарның авызын кулыңнан ычкындырма.
2. Шарның авызын шешә муенына кидер.
3. Хәзер шарны кабартып кара. Шар әз генә кабарыр да, туктар, чөнки аңа шешә эчендәге һава комачаулый, ә һаваны шешә муенына кидергән шар үзе чыгармый. Өрәсең, ул кабармый. **Тылсым түгелмени бу?**

Сәер авазлар

Лимонадтан бушаган ике литрлы шешә, бакыр акча һәм бер чынаяк су кирәк.

Эш тәртибе:

1. Буш, авызы капланмаган шешәне берничә минутка суыткычка куй.
2. Бакыр акчаны суда юешлә.
3. Суыткычтан алган шешә авызын юешләнгән акча белән капла.

Берничә секундтан акча сикерепсикереп шешә авызына бәреләә, чиерткән авазлар чыгара башлый. Бакыр акчаны шешә эчендәге салкын һава күтәрә, чөнки һава әкренләп җылына һәм киңәя бара, ул шешәдән чыкканда сәер авазлар ишетелә.



Салам-пипетка

Коктейль эчә торган салам, ике стакан кирәк.

Эш тәртибе:

1. Стаканнарның берсенә су сал да, бушы янына куй.
2. Саламны сулы стаканга тык.
3. Күрсәткеч бармак белән саламның югары башына бас та, буш стаканга күчер.
4. Саламнан бармакны ал, саламга кергән беркадәр су буш стаканга агып төшә. Моны күп тапкырлар кабатлап, суны стаканның берсеннән икенчесенә күчереп бетерә аласың.

Өйдәге аптечкада була торган пипеткалар да шушы принцип буенча эшли.





Салам-флейта

Коктейль эчә торган салам һәм кайчы кирәк.

Эш тәртибе:

1. А рәсемендә күрсәтелгәнчә, саламның бер башын 15 мм озынлыгында итеп җәй дә, кырыйларын кайчы белән кис. Флейтаның "теле" килеп чыкты.
2. Саламның икенче башыннан бер-берсеннән тигез ераклыкта өч тишек яса (Б рәсеме).
3. Флейта "телен" авызыңа ал да, өр. Билгеле бер урында, өрү көче җитәрлек булса, флейта уйный башлар. Бармак белән әле бер, әле икенче тишеген капласаң, флейтаның да тавышы үзгәрә. Бәлки берәр көй дә чыгарырсың?

Су тромбоны


Коктейль эчә торган салам (авылда яшәүче малайлар, кызлар гап-гади ашлык саламыннан файдалана алалар) һәм лимонадтан бушаган шешә кирәк.

Эш тәртибе:

1. Шешәнең 3/4 өлешен су белән тутыр да, аңа саламны тык.
2. Саламның өске ягына көч белән өр. (Рәсемгә кара). Саламның һәм иреннәрнең торышын туры китерсәң, су тромбоны авазлар чыгара башлар.
3. Саламны, өрә-өрә, аска-өскә йөртәсе. Аска төшкән саен тромбонның тавышы да түбәнәер киресенчә, өскә менгәндә югарыланыр.

Саламга су ничек керүгә карап, чыккан авазның югарылыгы йә түбәнлеге үзгәрәчәк.






Бәрәңгене ничек тишәргә?

Чи бәрәңге һәм коктейль өчен ике салам кирәк.

Эш тәртибе:

1. Бәрәңгене өстәлгә куй. Саламны бәрәңге өстеннән 10 сантиметр югарылыкка күтәр.
2. Кискен хәрәкәт белән бәрәңгегә керт. Ул аны тишә алмыйча бөгеләчәк (А рәсеме).
3. Хәзер икенче саламны ал да, тишеген бармагың белән капла.
4. Саламны көч белән бәрәңгегә бәр. Ул җиңел генә бәрәңгене тишеп чыгар.

Бармак белән саламны каплап, саламның ныклыгын һава ярдәмендә арттырдың. Шуңа ул бөгелмәде, ә бәрәңгене тиште.



Тәгәрмәч кебек



Дүрт салам һәм авыр китап кирәк.

Эш тәртибе:

1. Өстәлгә авыр китапны куеп, кулың белән этеп кара. Бу җиңел түгел, шактый көч сорый.
2. Саламнарны тезеп, китапны алар өстенә куй. Китап өстәл өстеннән, тәгәрмәчтәге кебек, үзе тәгәрәр.

Беренче очракта китап кытыршы өслектә шумады. Салам ярдәмендә әлеге каршылык җиңелде. Саламнар автомобиль тәгәрмәчләрен хәтерләтә, әйеме?

Иреккә омтыла

Бер салам, пластилин һәм сулы стакан кирәк.

Эш тәртибе:

1. Саламны сулы стаканга төзәү.
2. Саламга су суырт (А рәсеме).
3. Саламның югары тишеген телең белән капла, аннары саламны стаканнан чыгарып, түбәнге тишекне пластилин белән томала.
4. Саламны авыздан алып югары тишекне дә пластилин белән сыла.
5. Сулы саламны бер сәгатькә суыткычка куй.

Суыткычтан алыр вакыт җиткәч, күрерсең: саламнан пластилин башлы боз торбачык чыгып тора. Ничек болай булган, дисеңме? Катканда су киңәя һәм бар нәрсәне җимереп, иреккә омтыла.





Көчле газета

Озын линейка һәм газета кирәк.

Эш тәртибе:


1. Линейканы, яртысын чыгарып, өстәлгә куй.

2. Газетаны берничә кат бөкләп линейкага куй һәм чыгып торган өлешенә китереп сук (А рәсеме) Газета өстәлдән очып китәр.

3. Хәзер газетаны сүтелгән килеш линейкага куй (Б рәсеме) һәм линейканың чыгып торган өлешенә сук. Газета очмас.

Серен аңладыңмы? Предметның өслек мәйданы арткан саен, каршылык тору көче дә арта. Газета шуңа күрә "көчәйде" дә.







Әз-әзләп, әмма еш өр...

Кием элгеч, калын җеп, китап кирәк.

Эш тәртибе:

1. Китапны җепләр ярдәмендә кием элгеченә бәйлә.

2. Кием элгечен кер бавына эл.

3. Китап янына якынча 30 сантиметрга бас та, бөтен көчең белән өр. Китап әз генә чайкалыр, артыннан тагын өреп, аны нык итеп чайкалдыра аласың.

Әз-әзләп, әмма еш өреп, китапны бер, тик берәгәйле өргәнгә караганда ныграк чайкалдырырга була икән.



Рекорд авырлык

Бер бит кәгазь, буш пыяла банка һәм ике калай савыт кирәк.




Эш тәртибе:

1. Ике калай савытны бер-береннән 30 сантиметр ераклыкта итеп куй.
2. "Күпер" ясап кәгазьне өсләренә куй.
3. "Күпер"гә буш банканы куй, ул чыдатмый, бөгелә.
4. Хәзер кәгазьне А Б В Г рәсемнәрдәгечә итеп гармунлап бөклә.
5. Бу "гармунны" калай савытлар өстенә куй да, банканы яңадан элеккечә урнаштыр. Кәгазь бөгелми!





Кечкенә булса да, пәһлеваннарга тора



Бау ал да, үзеңнән көчлерәк кеше белән агач йә багана кырына кил.

Эш тәртибе:

1. Бауны агачка йә баганага берничә кат ура.
2. Көчлерәк кеше бауның озын ягын, ә син кыска ягын ал.
3. Көчле кеше бауны үзенә нык итеп тартсын, күпме тырышса да бауны тартып ала алмаячак.

Шул рәвешчә портларда корабльләр туктый. Бер матрос канат ярдәмендә зур корабльне причалга тартып китерә ала.


Көмеш кыңгырау

Баш мөхәррир
Нәсимә САДЫЙКОВА

Индекс - 31700
Тираж - 6895